**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.02.2020 пгт. Рыбная Слобода № 26пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләренә хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнүче персонал санын билгеләү буенча нормативны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан дәүләт эшләрен (хезмәт күрсәтүләрен) башкаруга (хезмәт күрсәтүгә) норматив чыгымнарны исәпләү тәртибен һәм дәүләт эшләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең норматив санын исәпләү методикасын раслау турында» гы 2013 елның 1 июнендәге 376 номерлы карары нигезендә, (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 17 июлендәге 500 номерлы карары үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) КАРАР БИРӘМ:

1.Мәдәният учреждениеләренә (авыл мәдәният йортлары, авыл клублары, китапханәләр, музейлар) хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнүче персоналның санын билгеләү буенча нормативны расларга. (1 нче кушымта).

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль-мәдәни сфера бүлеге» муниципаль казна учреждениесенә әлеге карарда билгеләнгән нормативның үтәлешен контрольдә тотарга тәкъдим итәргә.

3.Әлеге карарны Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда веб-адрес буенча : http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль-мәдәни сфера бүлеге» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе Р.Г.Рәшитовага йөкләргә.

Җитәкче Р. Л. Исланов

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 12 февралендәге 26пи номерлы карарына кушымта

## Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы мәдәният учреждениеләренә хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнүче персонал санын билгеләү буенча Норматив

| Вазыйфа атамасы | Ставкалар саны | Нигезләү: |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Җыештыручы | 1 штат берәмлеге | Җыела торган мәйданы 650 кв. м булган очракта кертелә. |